**СОВЕТ БЕРЕЗКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422712, Республика Татарстан, Высокогорский район
с.Березка, ул.Новостройка, д.15А

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КАЕНЛЫК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422712, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Каенлык авылы, Новостройка ур., 15А

Тел./факс: +7(84365) 79-2-08, e-mail: Berez.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**11 декабрь 2024 ел** **№ 128**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Березкино авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә,Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлеге Уставы белән, Татарстан Республикасы Биектау муниципальрайоны Каенлык авыл җирлеге Советы Карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы советына Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлеге башкарма комитетына түбәндәге вәкаләтләрне тапшыру турындагы мәсьәләне карауны тәкъдим итәргә: Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, аның предметы булып җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен үтәү тора.
2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимне кабул иткән очракта, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Каенлык авыл җирлеге башкарма комитетына: Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының башкарма комитеты белән килешү төзергә.
3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында, Биектау муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/.

Совет рәисе,
Каенлык авыл җирлеге Башлыгы А.Ә.Әминов